ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.07.2018 д. Канаш №12

Коену өчен кирәкле һәм җиһазланмаган урыннарда коенуны тыю турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау максатларында Россия Федерациясе Су кодексының 7 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, 06.10.2003 № 131-ФЗ маддәсе, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Канаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан су объектларында бәхетсезлек очракларын булдырмау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Канаш авыл җирлеге территориясендә коену өчен җиһазланмаган урыннарда һәм пляжларда гражданнарга су объектларында (сулыкларда һәм елгаларда) су коенудан тыелырга тәкъдим итәргә.
2. Канаш авыл җирлегендә коену урыннары һәм пляжлары җиһазланмаган территорияләрдә тиешле тыелган билгеләр урнаштырырга.
3. Әлеге карарны тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков